Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең
Колшәрип авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

4 декабрь 2023 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 1 декабрендә 10 сәгать 00 минутта, 2023 елның 1 декабрендә 11 сәгать 00 минутта, 2023 елның 1 декабрендә 12 сәгать 00 минутта, 2023 елның 1 декабрендә 13 сәгать 00 минутта, 2023 елның 1 декабрендә 14 сәгать 00 минуттаузган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге “Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге Колшәрип авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүһәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: урам яктырту челтәрләрен, су белән тәэмин итү системасын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау, су чыганакларыннан су алу, торак пункт чикләрендә гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын ремонтлау, смета төзү, җирлеккә техник күзәтү ясау, җирлек милкенә күзәтүне рәсмиләштерү өчен түләү сметасын төзү, җирлек милкенә күзәтүне рәсмиләштерү өчен бирү мәсьәләсен хәл итүгә юнәлтеп кертүгә сез 2024 елда үзара салым кертүгә килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1673 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 875 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 875 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ»позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге Колшәрип авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: урам яктырту челтәрләрен, су белән тәэмин итү системасын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау, су чыганакларыннан су алу, торак пункт чикләрендә гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын ремонтлау, смета төзү, җирлеккә техник күзәтү ясау, җирлек милкенә күзәтүне рәсмиләштерү өчен түләү сметасын төзү, җирлек милкенә күзәтүне рәсмиләштерү өчен бирү мәсьәләсен хәл итүгә юнәлтеп кертүгә сез 2024 елда үзара салым кертүгә килешәсезме?” турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Колшәрип авыл җирлеге башлыгы А.Ф.Кәшәфетдинов